**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 19 июнендәге 2106 номерлы карары**

## Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 11 маендагы 2118 номерлы карары белән расланган «Солтан Ай» территориясен планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү турында

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45 һәм 46 статьяларына туры китереп, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, вәкаләтле Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 11 маендагы 2118 номерлы карары белән расланган «Солтан Ай» территориясен планлаштыру проектына, әлеге карар кушымтасы нигезендә территорияне планлаштыру проектының аерым өлешләрен раслап, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 19 июнендәге
2106 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 11 маендагы 2118 номерлы карары белән расланган «Солтан Ай» территориясен планлаштыру проектына кертелгән үзгәрешләр**

1. Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, шулай ук территорияне план буенча үстерү характеристикалары, шул исәптән төзелешнең тыгызлыгы һәм параметрлары, территорияне үстерү өчен кирәкле социаль, транспорт хезмәте күрсәтү һәм инженерлык-техник яктан тәэмин итү системаларын үстерү характеристикалары турында нигезләмәдә:

1.1. 1.3 «Территорияне үстерү характеристикалары һәм социаль хезмәт күрсәтү системаларын үстерү характеристикалары, төзелеш параметрлары» пунктындагы 1 таблицага түбәндәге эчтәлекле юлны өстәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «25 | Спорт һәм сәүдә функциясе белән халыкка хезмәт күрсәтү объекты | - | - | 1500 кв.м | 4399,0 | -» |

1.2. 1.4 «Транспорт хезмәте күрсәтү системасын үстерү характеристикасы» пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Спорт һәм сәүдә функциясе белән халыкка хезмәт күрсәтү объекты өчен норматив буенча 31 машина урыны планлаштырыла торган объект кишәрлеге чикләрендә урнаштырыла»;

1.3. 1.6.1 «Су белән тәэмин итү» пунктында:

1.3.1. «1260» санын «1277,07» санына алмаштырырга;

1.3.2. түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектны Җиңү проспектында Аграр урамы белән киселештәге Ø1020 мм лы суүткәргеч челтәренә тоташтыру каралган. Проектлана торган территория өчен су белән тәэмин итүгә гомуми ихтыяҗ тәүлегенә 17,07 куб.м тәшкил итә. Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объект өчен су белән тәэмин итү челтәрләрен тоташтыру ноктасы

проектлаштыруның алдагы стадияләрендә төгәлләштерелергә мөмкин, территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү кирәк түгел»;

1.4. 1.6.2 «Су чыгару» пунктында:

1.4.1. «1066» санын «1079,32» санына алмаштырырга;

1.4.2. түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектны Җиңү проспектында Татарстан урамы белән киселештәге Ø600 мм лы канализация коллекторына тоташтыру каралган. Проектлана торган территориядә су чыгару буенча гомуми ихтыяҗ тәүлегенә 13,32 куб.м тәшкил итә. Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объект өчен су чыгару челтәрләрен тоташтыру ноктасы проектлаштыруның алдагы стадияләрендә төгәлләштерелергә мөмкин, территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү кирәк түгел»;

1.5. 1.6.3 «Яңгыр канализациясе» пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объект өчен ябык типтагы яңгыр канализациясе челтәрләрен төзү, алга таба 3 номерлы урамда каралган яңгыр канализациясе челтәрләренә тоташтыру күздә тотыла. Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объект өчен яңгыр канализациясе челтәрләрен тоташтыру ноктасы проектлаштыруның алдагы стадияләрендә төгәлләштерелергә мөмкин, территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү кирәк түгел»;

1.6. 1.6.4 «Электр энергиясен куллану» пунктында:

1.6.1. «2100» санын «2411» санына алмаштырырга;

1.6.2. түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектны электр белән тәэмин итү кертеп төзелгән трансформатор подстанциясе төзүне күздә тота. Тоташтыру 110 кВ лы Константиновка подстанциясеннән каралган. Объект егәрлегенә гомуми ихтыяҗ 311 кВт тәшкил итә. Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объект өчен электр белән тәэмин итү челтәрләрен тоташтыру ноктасы проектлаштыруның алдагы стадияләрендә төгәлләштерелергә мөмкин, территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү кирәк түгел»;

1.7. 1.6.6 «Газ белән тәэмин итү» пунктында:

1.7.1. «4581,9» санын «4601,9» санына алмаштырырга;

1.7.2. түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объект өчен газ көйләгеч пункт төзү. Черниково газ бүлеп тарату станциясенең югары басымлы газүткәргеченә тоташтыру каралган. Объектны газ белән тәэмин итүгә гомуми ихтыяҗ 20 куб.м/сәг. тәшкил итә. Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объект өчен газ

белән тәэмин итү челтәрләрен тоташтыру ноктасы проектлаштыруның алдагы стадияләрендә төгәлләштерелергә мөмкин, территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү кирәк түгел»;

1.8. түбәндәге эчтәлекле 1.8 «Территориядә төзелеш параметрлары, иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объект өчен капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләрендә капиталь төзелеш объектлары характеристикалары» пунктын өстәргә:

«1.8. Территориядә төзелеш параметрлары, иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объект өчен капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләрендә капиталь төзелеш объектлары характеристикалары:

3 таблица

| **Зонаның тәртип номерлары** | **Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру зоналары төрләре** | **Зона мәйданы, га** | **Рөхсәт ителгән файдалану төрләре кодлары (төп/ ярдәмче)** | **Объектларның билгеләнеше** | **Капиталь төзелеш объектларында катларның максималь саны** | **Торак фондының максималь гомуми мәйданы (мең кв.м)** | **Планлаштырыла торган объектлар турында мәгълүмат** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектларны урнаштыру зонасы | 0,44 | 4.4, 4.6, 5.1.2, 3.3, 3.1.1 | Шәхси милек | 3 | билгеләнмәгән | Спорт һәм сәүдә функциясе белән халыкка хезмәт күрсәтү объекты» |

2. Түбәндәге редакциядә V «Территорияне план буенча үстерү чираты турында нигезләмә» бүлеген өстәргә:

«V. Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объект өчен территорияне план буенча үстерү чираты турында нигезләмә.

Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектны проектлаштыру һәм төзү этабы территориянең планлаштырыла торган үсеше чиратына бәйле түгел.

4 таблица

Иҗтимагый-сәүдә билгеләнешендәге объектны
проектлаштыру һәм төзү вакытлары


| Этап | Зонаның тәртип номеры | Торак булмаган билгеләнештәге капиталь төзелеш объектлары | | |
| --- | --- | --- | --- | --- |
| | | Архитектура-төзелеш ягыннан проектлаштыру | Төзү | Сүтү |
| - | 1 | 2026 елның IV кварталы | 2030 елның III кварталы | -» |

1. Кызыл линияләрне, социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны, капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләрен күрсәтеп, планлаштыру проекты сызымы фрагментын әлеге үзгәрешләргә кушымта нигезендә бирергә.

I. Фрагмент Чертежа Проекта планировки с указанием красных линий, границ зон планируемого размещения объектов социально-культурного и коммунально- бытового назначения, объектов капитального строительства

Приложение к изменениям, вносимым в проект планировки территории "Султан Ай", утвержденный постановлением Исполнительного комитета г. Казани от 11.05.2018 №2118




| Условные обозначения | |
|---|---|
| Границы, линии градостроительного регулирования | |
| | граница территорий, в отношении которой осуществляется подготовка проекта планировки территории |
| | граница земельного участка |
| красная линия | действующая красная линия улично-дорожной сети |
| Зоны размещения | |
| 1 | порядковый номер зоны размещения |
| 5 | вид зоны размещения объектов капитального строительства |
| 0,0757 | площадь зоны размещения (га) |
| 3.4.1, 3.4.2 | код вида разрешенного использования |
| н.у | максимальная общая площадь жилищного фонда (тыс.кв.м.) |
| 3 | максимальная этажность (этаж) |
| 16:50:070116:10 | кадастровый номер участка |
| 5 | зона планируемого размещения объектов общественно-делового назначения |